Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге
Бәйрәкә торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 2 12 ноябрь 2024 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге Бәйрәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (тормыш иптәше, ата-аналары, балалары) тыш, 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы; әлеге түләүне бер тапкырга киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- Бәйрәкә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистартуга (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчы белән техниканы арендалау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));
- Бәйрәкә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Абдуллин урамындагы юл-урам челтәрен (чокырларны ремонтлау) норматив хәлгә китерү);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, электр тарату пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлауга (лампалар, энергияне сак тота торган яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерүгә (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- халыкның күпләп ял итә торган урыннарын (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзекләндерүгә һәм аларга якын территорияне төзекләндерүгә;

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су жыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүгә (материаллар, җайланмалар сатып алу, су агып яту урыннарын бетерү, торбаларны алыштыру, эш өчен килешү буенча түләү).

- Бәйрәкә торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар тоту, (зират территориясендә карт агачларны кисү, агачларны химик эшкәртү (химик препарат сатып алу), эш өчен килешү буенча түләү)) юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында эләргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина